ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.05.2020 ел Баулы шәһәре №101

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
27 декабрендәге 344 номерлы карары
белән расланган Ташламалы транспорт
картасы һәм балалар ташламалы
транспорт картасы буенча гражданнарга
транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле
транспорт оешмаларына Баулы муниципаль
районы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибенә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив-хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 887 номерлы карары (2019 елның 26 декабрендәге редакциясендә) нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 декабрендәге 344 номерлы карары белән расланган Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле транспорт оешмаларына Баулы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- транспорт оешмасының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган бурычлары булмаска тиеш;».

2. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм

http://www.bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров